ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
01.06.2026

**К А Р А Р**
№ 421

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе хакында**

Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 2811 статьясы, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы, «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль законнар, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының түбәндәге карарларын үз көчләрен югалткан дип танырга:

- «Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат һәм Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» 2013 елның 14 мартындагы 662 номерлы;
- «Биектау муниципаль районы җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат һәм Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру хакындагы нигезләмәне раслау турында» Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 14 мартындагы 662 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 16 сентябрендәге 1795 номерлы;
- «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль

учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 20 июлендәге 720 номерлы.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында https://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында https://pravo.tatarstan.ru халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

5. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты» МКУ эшләр идарәчесе Г.Ф. Сабировага йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф.Хәкимуллин

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 01.06.2026 елның 421нче номерлы карары белән расланды

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру тәртибе**

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат, шулай ук Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы муниципаль учреждениесе җитәкчеләре тарафыннан үзләренең керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда каралган хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре хакында белешмәләр (алга таба - керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр) тапшыру процедурасын билгели.

2. Керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетына (алга таба – эш бирүче) түбәндәгеләр тарафыннан тапшырыла:

муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре вазыйфаларына эшкә керүче затлар тарафыннан;

муниципаль учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан - «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта.

3. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат эшкә кергәндә муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керергә документлар тапшыру елына кадәрге календарь ел өчен барлык чыганаклардан алынган керемнәре турында (элекке эш урыны яисә сайланулы вазыйфаны биләү урыны буенча керемнәрен, пенсияләрен, пособиеләрен һәм башка түләүләрне кертеп), милек хокукында аныкы булган мөлкәте турында һәм муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аена кадәрге айның беренче числосына үзенең мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук зат тарафыннан муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшырылган елга кадәрге календарь ел өчен үзләренең хатынының

(иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан алынган керемнәре турында (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне һәм башка түләүләрне кертеп) белешмәләрне, шулай ук милек хокукындагы мөлкәте хакында һәм муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына керү өчен документлар тапшыру аеннан алдагы айга кадәр айның беренче числосына мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләрне тапшыра.

4. «Дәүләт вазыйфаларын биләүче затларның һәм башка затларның чыгымнарының аларның керемнәренә туры килүен контрольдә тоту турында» 2012 елның 3 декабрендәге 230-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе мондый нигезләр барлыкка килгән елдан соң килүче елның 30 апреленнән дә соңга калмыйча түбәндәгеләрне тапшыра:

чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чоры) барлык чыганаклардан (акчалата бүләкләүне, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне дә кертеп) алынган үзенең керемнәре турында белешмәләр, шулай ук хисап чоры ахырына милек хокукында аныкы булган мөлкәте хакында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр;

чыгымнар турында белешмәләр тапшыру өчен нигезләр барлыкка килгән елның 1 гыйнварыннан 31 декабренә кадәр (хисап чоры) хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының барлык чыганаклардан (хезмәт хакын, пенсияләрне, пособиеләрне, башка түләүләрне кертеп) алынган керемнәре турында белешмәләр, шулай ук милек хокукында аларныкы булган мөлкәте турында һәм хисап чоры ахырына торышы буенча мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр.

5. Әлеге Тәртипнең 3 һәм 4 пунктларында каралган белешмәләр «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы» МБ МКУнең кадрлар бүлегенә Россия Федерациясе Президентының «Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмә формасын раслау һәм Россия Федерациясе Президентының кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2014 елның 23 июнендәге 460 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе Президентының рәсми сайтында урнаштырылган «БК белешмәләре» махсус программа тәэминатын кулланып тутырылган форма буенча Килешү нигезендә тапшырыла, аңа сылтама шулай ук дәүләт хезмәте өлкәсендә федераль дәүләт мәгълүмат системасының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырыла.

6. Әгәр муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә керүче зат керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең чагылыш тапмавын яисә тулысынча чагылыш тапмавын йә хаталар булуын ачыкласа, ул белешмәләр тапшырылган көннән алып бер ай эчендә әлеге Тәртипнең 3 пункты нигезендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшыра.

7. Әгәр муниципаль учреждение җитәкчесе керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында үзе тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса белешмәләрнең чагылдырылмавын яисә тулысынча чагылдырылмавын йә хаталар булуын ачыкласа, ул төгәлләштерелгән белешмәләрне әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә тапшыра.

8. Әлеге Тәртип нигезендә тапшырыла торган керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турындагы белешмәләр, әгәр федераль законнар тарафыннан алар дәүләт серен һәм федераль законнар белән саклана торган башка серне тәшкил итә торган белешмәләргә кертелмәгән булса, конфиденциаль характердагы белешмәләр булып тора.

9. Әлеге Тәртип нигезендә керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырган зат муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына билгеләнмәгән очракта, күрсәтелгән белешмәләр аңа язма гаризасы буенча башка документлар белән бергә кире кайтарыла, ә язма гариза булмаганда юкка чыгарылырга тиеш.

10. Аңа бәйле булмаган хәлләр аркасында керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру мөмкин булмаган очракта, муниципаль учреждение җитәкчесе бу хакта «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясында каралган тәртиптә һәм срокларда эш бирүченең хезмәт тәртибенә карата таләпләрне үтәү һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комиссиягә хәбәр итәргә тиеш.

11. Муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына эшкә кергәндә затның керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавы йә белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тапшыруы күрсәтелгән затны муниципаль учреждение җитәкчесе вазыйфасына кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора.

12. Муниципаль учреждение җитәкчесе тарафыннан керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмавы йә дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр тапшыруы эш бирүче тарафыннан аңа ышанычны югалтуга бәйле рәвештә аның белән төзелгән хезмәт шартнамәсен өзү өчен нигез булып тора (Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 81 статьясындагы 1 өлешенең $7^1$ пункты).